КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 июнь

г.Казань

№ 523

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагый-дәләрен раслау турында» 2019 ел, 13 июль, 582 нче карары белән расланган Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 13 июль, 582 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 17 октябрь, 921 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1261 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Инвалидларны,

шул исәптән инвалид балаларны комплексды тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын форма-лаштыру чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «шәхси счетка» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетына» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интегральләшкән мәгълүмат системасыннан файдаланып төзелгән федераль бюджеттан субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән рәвешләр һәм сроклар буенча хисаплар тапшыра.»;

10 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасыннан файдаланып төзелгән федераль бюджеттан субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән рәвешләр һәм сроклар буенча хисапларны Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына тапшыра.»;

12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин